СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2021 с. Сарманово №56

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2019 елның 7 октябрендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2019 елның 7 октябрендәге 194 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 37 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:
«-Россия Федерациясенең илкүләм үсеше максатларын һәм халыкка гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документларда;»
2) 37 статьяның 2 пунктында өченче - җиденче абзацларны дүртенче - сигезенче абзацлар дип санарга;
3) 9 статьяның 9 пунктындагы 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акча түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына бирә;
4) 35 статьяның 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кредит (облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия, кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заем бирүче) йөкләмәләрен бирү турында шартнамәдә күрсәтелгән кредит (заем) акчаларының максатчан кулланылуын үз ягыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру шарты белән бирелә.